Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлегенең Алших авылында гражданнар җыены карары

16.11.2023 № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Буа муниципаль районы Алших авыл җирлегенең Алших авылында гражданнар җыены

КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. 2024 елда Алших авыл җирлегенең Алших авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәм сайлау хокукына ия балигъ булган гражданнарның һәркайсыннан 500 сум күләмендә үзара салым җыюны кертергә.

2. Җыелган акчаны түбәндәге җирле мәсьәләләрне хәл итүгә

- Алших авылында юлларны төзекләндерүгә, зиратларга илтә торган юлларны ремонтлау, зиратта часовня төзү, зиратны төзекләндерү, кышкы чорда юлларны карап тоту, җәйге вакытта территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү) өчен юнәлдерергә.

3. Җыен нәтиҗәләрен Алших авыл җирлегенең Алших авылында махсус җиһазландырылган мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Алших авыл җирлеге башлыгы _____ А.П. Андреев

Гражданнар җыены секретаре _____ Л.Р. Сагдеева